ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

2022 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон проекты эшенең якынча планы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. 2022 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон проекты эшенең якынча планын расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Закон чыгару инициативасы хокукына ия субъектлар 2022 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон проекты эшенең якынча планы нигезендә закон проектларын үз вакытында әзерләүне һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына кертүне тәэмин итәргә тиеш.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының тиешле комитетлары эшчәнлеген җайга салучы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасарлары 2022 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон проекты эшенең якынча планына кертелгән закон проектларын әзерләү срокларын үтәүне контрольдә тотуны билгеләргә тиеш.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2021 елның 24 декабре
№ 1282-VI ДС

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советының
2021 елның 24 декабрендәге
1282-VI ДС номерлы
карарына кушымта

**2022 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон проекты эшенең якынча планы**

| № т/б | Проектның исеме | Закон чыгару инициативасы хокукы субъекты | Проектны Татарстан Республикасы Дәүләт Советына тапшыру вакыты |
|---|---|---|---|
| 1 | Россия Федерациясе Конституциясенә төзәтмәләр хакында «Гавами хакимиятне оештыруның һәм аның эшчәнлегенең аерым мәсьәләләрен җайга салуны камилләштерү турында» 2020 елның 14 мартындагы 1-ФКЗ номерлы Россия Федерациясе Законын, «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль законны һәм аларны үстерүгә кабул ителгән федераль законнарны гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән Татарстан Республикасы законнары проектлары | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары | Ел дәвамында |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | **1. Дәүләт корылышы** | | |
| 2 | «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (федераль законнарга туры китерү өлешендә) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты | II квартал |
| 3 | «Татарстан Республикасы Конституция судын бетерү турында» Татарстан Республикасы законы проекты | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты | III квартал |
| 4 | «Татарстан Республикасы Сайлау кодексына һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты (закон актларының аерым нормаларын «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законндагы үзгәрешләргә туры китерү өлешендә) | Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе | IV квартал |
| 5 | «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (экспертиза (муниципаль норматив хокукый актларга (муниципаль норматив хокукый актлар проектларына) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты | IV квартал |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | җайга салу йогынтысын бәяләү) үткәрү мәҗбүри булган муниципаль районнар һәм шәһәр округлары исемлеген төгәлләштерү өлешендә) | | |
| 6 | «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламенты турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2004 елның 26 февралендәге 2632 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты (Татарстан Республикасы законнарына туры китерү өлешендә) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Ш.Ш. Яһудин | IV квартал |
| **2. Икътисадый сәясәт** | | | |
| 7 | «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законны гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты («Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законны гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законына мониторинг нәтиҗәләре буенча аерым | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитеты | II квартал |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | нигезләмәләрне актуальләштерү өлешендә) | | |
| 8 | «2021 елгы Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында» Татарстан Республикасы законы проекты (Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $97^4$ статьясы нигезендә) | Татарстан Республикасы Президенты | II квартал |
| 9 | «2021 елгы Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты үтәлеше турында» Татарстан Республикасы законы проекты (Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $97^6$ статьясы нигезендә) | Татарстан Республикасы Президенты | II квартал |
| 10 | «Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарының (шул исәптән Россия Федерациясе субъектларына Россия Федерациясе вәкаләтләре бирелгәннәрнең) һәм җирле үзидарә органнарының урман мөнәсәбәтләре өлкәсендәге вәкаләтләрен төгәлләштерү өлешендә) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты | II квартал |
| 11 | «2023 елга Татарстан Республикасында хезмәт базары үзенчәлекләрен чагылдыра торган региональ коэффициентны билгеләү турында» Татарстан Республикасы законы проекты (патент нигезендә физик һәм юридик затларда хезмәт эшчәнлеген наем буенча | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты | III квартал |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | гамәлгә ашыручы чит ил гражданнарының физик затлар керемнәренә салым буенча теркәлгән түләүләр күләмен индексацияләү Россия Федерациясе субъекты законы белән тиешле календарь ел өчен хезмәт базарының региональ үзенчәлекләрен чагылдыра торган коэффициентны билгеләү күздә тотылган Россия Федерациясе Салым кодексының $227^1$ статьясындагы 3 пункты нигезендә эшләнә) | | |
| 12 | «Татарстан Республикасында автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының автомобиль юлларыннан файдалану һәм юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру өлкәсендәге вәкаләтләрен төгәлләштерү өлешендә) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитеты | III квартал |
| 13 | «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты (федераль законнарга туры китерү өлешендә) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты | III квартал |
| 14 | «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (махсус икътисадый зона идарәче компанияләренең мөлкәтен салым салудан азат итү өлешендә) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Т.Н. Шаһивәлиев | III квартал |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 15 | «Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәте турында» Татарстан Республикасы Законының 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (федераль законнарга туры китерү өлешендә) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты | IV квартал |
| 16 | «2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы законы проекты (Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 61 статьясы нигезендә) | Татарстан Республикасы Президенты | IV квартал |
| 17 | «2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы законы проекты (Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 61 статьясы нигезендә) | Татарстан Республикасы Президенты | IV квартал |
| **3. Социаль сәясәт** | | | |
| 18 | «Татарстан Республикасында хезмәтне саклау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының хезмәтне саклау өлкәсендә мөнәсәбәтләрне җайга салу вәкаләтләрен билгеләү өлешендә) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты | I квартал |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 19 | «Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (федераль законнарга туры китерү өлешендә) | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты | I квартал |
| 20 | «Татарстан Республикасы территориясендә балигъ булмаганнарга тонус бирүче алкогольсез эчемлекләрне ваклап сатуга чикләүләр билгеләү турында» Татарстан Республикасы законы проекты | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты | II квартал |
| 21 | «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (пай җирләре мәйданын мөлкәти тәэмин ителеш критерийларыннан төшереп калдыру өлешендә) | Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советы | II квартал |
| 22 | «2023 елга Татарстан Республикасы гомуми белем бирү һәм һөнәри белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» Татарстан Республикасы законы проекты («Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль законның $26^3$ статьясы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты | III квартал |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | һәм «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясы нигезендә) | | |
| 23 | «2023 елга Татарстан Республикасында мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» Татарстан Республикасы законы проекты («Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль законның $26^3$ статьясы һәм «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясы нигезендә) | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты | III квартал |
| 24 | «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты («Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законы нормаларын актуальләштерү һәм аның аерым нигезләмәләрен федераль законнарга туры китерү максатында) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты | IV квартал |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **4. Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасында Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативалары** | | | |
| 25 | «Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүматны яклау турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проекты («Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтның домен исемнәре атамасында һәм битләрендә товар билгеләренә хокукка ия булучыларның аерым хокукларын яклау өлкәсендә бушлыкларны юкка чыгару максатларында) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты И.Ә. Шамилов | III квартал |